**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 24 март № 179

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 ел, 18 гыйнвар, 9 нчы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алу буенча мөрәҗәгать итү һәм аны түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 ел, 18 гыйнвар, 9 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 апрель, 167 нче; 2007 ел, 5 октябрь, 533 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 март, 171 нче; 2008 ел, 25 июнь, 429 нчы; 2009 ел, 27 март, 179 нчы; 2010 ел, 1 февраль, 49 нчы; 2012 ел, 15 май, 376 нчы; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 31 август, 620 нче; 2014 ел, 21 май, 338 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Компенсация алу өчен гариза бирүче Татарстан Республикасы территориясендәге яшәү урыны (әгәр гариза бирүче яшәү урыны буенча

теркәлмәгән булса, тору урын) буенча Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлегенә, ә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән гражданнар өчен – тиешле мәгариф оешмасы теркәлгән урын буенча түбәндәге документларны тапшыра:

банкта яки бүтән кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп (компенсацияне банкта яки бүтән кредит оешмасы аша алганда), компенсация билгеләү турында гаризаны;

компенсация билгеләнгән баланың туу (уллыкка (кызлыкка) алу) турында таныклыгы күчермәсе – бала (балалар) туу Татарстан Республикасыннан читтә дәүләт теркәвенә алынган очракта;

компенсация билгеләнгән баладан алдарак туган, әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә гариза бирүче гаиләсе составында исәпкә алынган баланың (балаларның) туу (уллыкка (кызлыкка) алу) турында таныклыгы күчермәсе – бала (балалар) туу Татарстан Республикасыннан читтә дәүләт теркәвенә алынган очракта;

18 яшьтән алып 23 яшькәчә балаларның йөреп уку рәвешендә укулары турында белем бирү оешмасыннан белешмә кәгазе;

баланы тиешле белем бирү оешмасына урнаштыру турында шартнамә күчермәсе – 2015 елның 30 сентябренә кадәр мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән затлар өчен;

баланың табель саны турында мәгълүматларны үз эченә алган (мәктәпкәчә белем бирү оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен түләү квитанциясе копиясен) документ (документ күчермәсе) – 2015 елның 30 сентябренә кадәр мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән затлар өчен;

гариза ышанычлы зат тарафыннан бирелсә, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсе.

Документлар күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булса, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла.

Гариза бирүче яки ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән зат мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документ күрсәтә.»;

8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлеге ведомствоара сорату нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати багланышлар системасыннан файдаланып электрон рәвештә түбәндәгеләрне ала:

компенсация билгеләнгән баланың тууын (уллыкка (кызлыкка) алуны) дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр – бала туу Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракта;

компенсация билгеләнгән баладан алдарак туган, әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә гариза бирүче гаиләсе составында исәпкә алынган баланың (балаларның) тууын (уллыкка (кызлыкка) алуны) дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр – бала (балалар) туу (уллыкка (кызлыкка) алу) Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракта;

балага опека билгеләү турында белешмәләр;

баланы тәрбиягә алган гаиләгә бирү турында белешмәләр;

алучыны ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукын чикләү турында белешмәләр;

баланы тиешле белем бирү оешмасына урнаштыру турында шартнамә төзегән зат турында мәгълүматлар – 2015 елның 30 сентябренә кадәр мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән  шартнамә төзегән затлар өчен;

мәктәпкәчә белем бирү оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен түләү квитанциясендә күрсәтелгән табель саны турында мәгълүматлар – 2015 елның 30 сентябренә кадәр мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән  шартнамә төзегән затлар өчен.

Компенсация алу максатларында гариза бирүче яки ул ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр биргән зат үз башлангычлары белән Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлегенә әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны шул исәптән электрон документ рәвешендә дә тапшыра ала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков